**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Чубар-Абдулловского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Советская, д. 81 , село Чубар-Абдуллово
Азнакаевского муниципального района, 423323
Тел. (факс) (85592)38-7-37
Chabd.Azn@tatar.ru

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авылы
Азнакай муниципаль районы, 4233237
Тел. (факс) (85592) 38-7-37
Chab.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» март 2024 ел № 3

«2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлегенең Мяндей торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 2023 елның №1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең Мяндей торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында»гы, 2023 елның №2 карарлары буенча «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлегенең Мяндей торак пунктында гражданнарның җыенын билгеләү хакында»

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «2024 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы карары, Чубар-Абдул авыл җирлеге Мяндей торак пунктының 25.1 Уставы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге муниципаль берәмлек Башлыгы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. «2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлегенең Мяндей торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 2023 елның №1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең Мяндей торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында»гы 2023 елның №2 карарлары буенча 2024 елның 18 мартында 14 сәгать 00 минутта гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең Мяндей торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 25.11.2023 ел № 1, «Мяндей торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертүе турында» 25.11.2023 ел № 2 гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (светодиодлы лампаларны сатып алу, урнаштыру);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен ремонтлау (грейдер белән юлларны тигезләү, контракт буенча эш өчен түләү)

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Азнакай муниципаль районының мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында (http:// aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы _______________ Н.Ә. Фәтхетдинов